# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Һөнәр берлекләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 31 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Һөнәр берлекләре турында" 1995 елның 18 гыйнварындагы 2303-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1995, № 1; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның өченче өлешендә "тикшереп тору органнары" сүзләреннән соң ", Россия Федерациясе Тикшерү комитеты" сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяда:
а) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
б) өченче өлештә ", һәм шушы дәвердә аның өзлексез эш стажы саклана" сүзләрен төшереп калдырырга;
в) дүртенче өлештә ", өзлексез" сүзен төшереп калдырырга, "эш стажына" сүзләрен "хезмәт стажына" сүзләренә алмаштырырга;

3) 20 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"21 статья. **Эштән азат иткәндә сайланулы һөнәр берлекләре хезмәткәрләре өчен гарантияләр**

Эш бирүче инициативасы белән башлангыч һөнәр берлекләре оешмаларының сайланулы коллегиаль органнарының, оешмалардагы структур бүлекчәләрнең

һөнәр берлекләре оешмаларының сайланулы коллегиаль органнарының (цехлардан һәм аларга тигезләштергәннәрдән ким түгел) төп эшеннән азат ителмәгән җитәкчеләрен (аларның урынбасарларын) эштән азат итү Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган тәртиптә рөхсәт ителә.

Башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы җитәкчесе һәм аның урынбасарлары белән эш бирүче инициативасы буенча аларның вәкаләтләр чоры тәмамланганнан соң ике ел дәвамында хезмәт шартнамәсен өзү, оешма хезмәткәрләренең саны яисә штаты кыскартылган очракта, аттестация нәтиҗәләре белән расланып, хезмәткәр, квалификациясе җитмәгәнлектән, били торган вазыйфасына яки башкара торган эшенә туры килмәгән очракта яисә хезмәткәр, әгәр ул дисциплинар җәзага тартылган булса, хезмәт бурычларын нигезсез сәбәпләр аркасында берничә тапкыр үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган тәртипне үтәгән килеш кенә рөхсәт ителә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 18 апреле
№ 10-ТРЗ